РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____19.03.2018______ __296-п______

Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда
катнашучыларны һәм аларның җитәкчеләрен
матди яктан тәэмин итү өчен сарыф ителгән
акчаларның нормасын һәм тәртибен раслау хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына карата яшьләр сәясәтен үстерүне хуплау, аларның активлыкларын куәтләү өчен яшьләр эшчәнлекләрен стимуллаштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда җиңүчеләрне һәм аларның җитәкчеләрен матди яктан бүләкләү өчен тотылган чыгымнарның нормасын һәм Тәртибен расларга.

**2.** Әлеге карарны информацион-телекоммуникацион “Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресындагы Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресындагы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.03.2018 даталы 296-п номерлы
карары нигезендә
РАСЛАНГАН

# Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда катнашучыларны һәм аларның җитәкчеләрен матди яктан тәэмин итү өчен сарыф ителгән акчаларның нормасы һәм Тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

**1.1.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда катнашучыларны һәм аларның җитәкчеләрен матди яктан тәэмин итү өчен сарыф ителгән акчаларның нормасы һәм Тәртибе Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының агымдагы ел казнасында каралган акчалар исәбенә үткәрелә торган чараларга кагыла.

**1.2.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларга фестивальләр, акцияләр, форумнар, конкурслар, төрле уеннар, слетлар кагыла.

**1.3.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда катнашучыларга яшьләр (14 яшьтән алып 30 яшькә кадәр), җәлеп ителгән белгечләр, чараны оештыруда һәм үткәрүдә катнашучылар керә.

**1.4.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда катнашучыларны юнәлдерү оешмаларның рәсми чакыруы, аны үткәрүчеләр яки чараны үткәрү турындагы торышы нигезендә ашырыла.

**1.5.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларны үткәрүче оешмаларга Саба муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре (спорт һәм яшьләр эшләре бүлеге, уку-укыту бүлеге, мәдәният бүлеге), Саба муниципаль районы казнасы исәбеннән финансланучы башка органнар, оешмалар, яшьләр өлкәсе юнәлешендәге оешмалар кагыла.

## 2. Акчаларны сарыф итү тәртибе

**2.1.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларны билгеләнгән тәртиптә үткәргәндә раслана:

- чараларны үткәрү турындагы торышлары (регламентлары), аларның тәртибе, чит ил делегацияләренең килү программалары, башка регламентлаучы документлар;
- яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда катнашучыларның санлы составын кертүче чыгым сметасы.

**2.2.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда катнашучыларның һәм аларның җитәкчеләрен акчалата бүләкләү, башкарылган эш өчен хезмәт күрсәтүче персоналга һәм белгечләргә түләү, ашау, яшәү өчен тотылган чыгымнар билгеләнгән нормалар нигезендә башкарыла.

**2.3.** Муниципаль районның Башкарма комитеты белән төзелгән килешүләр нигезендә район территориясендә яшьләр сәясәте өлкәсендәге халыкара чараларны үткәрү, чит ил вәкилләренә хезмәт күрсәтү һәм аларны кабул итү өчен тотылган чыгымнарны Саба муниципаль районның Башкарма комитеты җитәкчесенең тиешле карары белән расланган чит ил вәкилләрен һәм аерым затларга хезмәт күрсәтү һәм аларны кабул итү өчен акчаларны сарыф итүнең гамәлдәге нормалары буенча башкарыла.

**2.4.** Катнашучыларның барлык категориясенә дә, чаралар үткәрү урынына килгәндә юлда булган вакыт өчен, район территориясендә куелганча акчалар түләнә, чараларны үткәрү көннәрендә катнашучыларның барлык категорияләре дә туклану белән тәэмин ителә.

**2.5.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда катнашучыларны һәм аларның җитәкчеләрен, белгечләрне командировкалау буенча чыгымнарны кайтару, хезмәт командировкалары өчен билгеләнгән нормалар буенча башкарыла.

**2.6.** Бина һәм җиһазларны арендалау, транспорт, почта-телеграф, типография, канцелярия һәм башкалар өчен чыгымнар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чараларны иң рациональ үткәрүне һәм чараларны куллануны тәэмин итә торган, чара уздырылган көнне гамәлдә булган бәяләр яки сөйләшенгән бәяләр күләмендә башкарыла.

**2.7.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларга хезмәт күрсәтүгә җәлеп ителгән белгечләрнең (медицина хезмәткәрләре, эшчеләр, радистлар, рәссамнар, машинисткалар, мотористлар һәм башкалар) күрсәткән хезмәтләре өчен түләү Россия Федерациясенең хезмәт турындагы гамәлдәге законнары нигезендә башкарыла.

**2.8.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларны бюджеттан тыш чаралар, шулай ук иганәчеләр, катнашулырның кертеме (оешмалар һәм башка җәлеп ителгән чыганаклар), акчасы хисабына үткәрүче оешмалар әлеге карар белән билгеләнгән нормалардан тыш түләүне арттырырга хокуклы.

## 3. Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларны финанслау тәртибе

**3.1.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларны оештырганда чыгымнар өчен җаваплы:

- чараларны үткәрә торган оешмалар - бина һәм җиһазларны арендалау, белгечләргә тәләү, җиңүчеләрне бүләкләү, хезмәт күрсәтүче персоналны тәэмин итү, почта-телеграф, типография, канцелярия, транспорт һәм башка хезмәтләр, катнашучыларны тукландыру һәм урнаштыру буенча;
- чараларда катнаша торган оешмалар – катнашучыларның командировкалау (юл өчен түләү, чаралар үткәрү көннәрендә ашату һәм урнаштыру) буенча.

**3.2.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чаралар, катнаша торган оешмаларның гариза кертемнәрен алу юлы белән кергән акчаларны кулланып үткәрелергә мөмкин. Шул исәптән, чыгымнар составы һәм гариза кертемнәренең күләме әлеге чараны оештыручы оешма тарафыннан раслана.

**3.3.** Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларны үткәрүгә кагылышлы, әлеге кушымтага кермәгән барлык чыгымнар, мәгълүматны бирү яки күрсәтелгән хезмәтләр өчен аңлатмалы бәяләре буенча исәп-хисаплана.

## 4. Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларны үткәргәндә катнашучыларны, аларның җитәкчеләрен һәм хезмәт күрсәтүче персоналны, белгечләрне тукландыру һәм яшәү өчен тотылган чыгымнаның нормалары.

| № ч\б | Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларны үткәрү территориясе | Бер катнашучыга бер көнгә чыгымнар нормасы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Саба районы территориясендә туклану | 300 кадәр |
| | ТР һәм РФ территориясендә туклану | 300 |
| | Министрлык һәм башка югары оешмаларның боерыклары, нигезләмәләре, регламентлары һәм хатлары нигезендә ТР һәм РФ территориясендә туклану | 900 кадәр |
| 2 | ТР территориясендә яшәү | 550 кадәр |
| | Министрлык һәм башка югары оешмаларның боерыклары, нигезләмәләре, регламентлары һәм хатлары нигезендә ТР һәм территориясендә яшәү | 1000 кадәр |
| | РФдә яшәү, ТР чигеннән тыш | 2000 кадәр |
| | РФ чигеннән читтә яшәү | 2500 кадәр |

## 5. Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда хезмәт күрсәтүче белгечләргә түләү күләме

| № ч/б | Чараларның дәрәҗәсе | Вазифа | Бер катнашучыга чыгымнар нормасы (бер көнгә сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | Район күләмендәге чаралар | Директор, чараларның җитәкчесе | 800 кадәр |
| | | Медицина хезмәте | 300 кадәр |
| | | Чараларга хезмәт күрсәтү | 300 кадәр |
| | | Яшьләр сәясәтенең төрле юнәлешләре буенча мастер-класслар үткәрү | 5000 кадәр |

## 6. Яшьләр сәясәте өлкәсендәге чараларда җиңүчеләргә һәм аларның җитәкчеләренә бирелгән истәлекле бүләкләрнең бәясе

| № ч/б | Чараларның дәрәҗәсе | Алынган урын | Бүләкләрнең бәясе, сумнарда | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Командалы ( команданың бер әгъзасына исәпләп) | Шәхси |
| 1. | Район күләмендәге чараларда бүләкле урыннар алган катнашучылар | I<br><br>II<br><br>III | 1000 кадәр команданың бер әгъзасына<br>900 кадәр команданың бер әгъзасына<br>800 кадәр команданың бер әгъзасына | 1000 кадәр<br><br>900 кадәр<br><br>800 кадәр |
| 2. | Республика күләмендәге чараларда бүләкле урыннар алган катнашучылар | I<br><br>II<br><br>III | 3000 кадәр команданың бер әгъзасына<br>2500 кадәр команданың бер әгъзасына<br>2000 кадәр команданың бер әгъзасына | 3000 кадәр<br><br>2500 кадәр<br><br>2000 кадәр |
| 3. | ПФО күләмендәге чараларда бүләкле урыннар алган катнашучылар | I<br><br>II<br><br>III | 4000 кадәр команданың бер әгъзасына<br>3500 кадәр команданың бер әгъзасына<br>3000 кадәр команданың бер әгъзасына | 4000 кадәр<br><br>3500 кадәр<br><br>3000 кадәр |
| 4. | Бөтенроссия күләмендәге чараларда бүләкле урыннар алган катнашучылар | I<br><br>II<br><br>III | 10000 кадәр команданың бер әгъзасына<br>8000 кадәр команданың бер әгъзасына<br>6000 кадәр команданың бер әгъзасына | 10000 кадәр<br><br>8000 кадәр<br><br>6000 кадәр |
| 5. | ТР, РФ территориясендә һәм РФ чигеннән читтә үткәрелүче халыкара күләмендәге чараларда бүләкле урыннар алган катнашучылар | I<br><br>II<br><br>III | 3000 кадәр команданың бер әгъзасына<br>1500 кадәр команданың бер әгъзасына<br>1000 кадәр команданың бер әгъзасына | 3000 кадәр<br><br>1500 кадәр<br><br>1000 кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Республика күләмендәге чараларга катнашучылар әзерләгән җитәкчеләр (катнашучының алган урынына карап) | I<br>II<br>III | 3000 кадәр<br>2000 кадәр<br>1000 кадәр |
| 7. | ПФО күләмендәге чараларга катнашучылар әзерләгән җитәкчеләр (катнашучының алган урынына карап) | I<br>II<br>III | 4000 кадәр<br>3000 кадәр<br>2000 кадәр |
| 8. | Бөтенроссия күләмендәге чараларга катнашучылар әзерләгән җитәкчеләр (катнашучының алган урынына карап) | I<br>II<br>III | 5000 кадәр<br>4000 кадәр<br>3000 кадәр |
| 9. | ТР, РФ территориясендә һәм РФ чигеннән читтә үткәрелүче халыкара күләмендәге чараларга катнашучылар әзерләгән җитәкчеләр (катнашучының алган урынына карап) | I<br>II<br>III | 3000 кадәр<br>1500 кадәр<br>1000 кадәр |